РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Аксубаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Аксубай муниципаль
районы башкарма
комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

« 01 » 02 2021 — № 35

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «2018-2022 елларда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә «Уңайлы шәһәр тирәлеген формалаштыру» өстенлекле проектын тормышка ашыру чаралары турында» 2017 елның 14 ноябрендәге 764 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2020 ел, 23 декабрь, 52682-МЕ/06 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «2018-2022 елларда Татарстан Республикасы Аксубай районы территориясендә «уңайлы шәһәр тирәлеген формалаштыру» өстенлекле проектын тормышка ашыру чаралары турында» 2017 ел, 14 ноябрь, 764 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Тәкъдимнәр бирү тәртибе һәм сроклары» 2 пунктның 2.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2018-2022 елларда «Уңайлы шәһәр тирәлеген формалаштыру» өстенлекле проектын тормышка ашыру кысаларында төзекләндерелергә тиешле җәмәгать территорияләрен сайлау һәм 2018-2022 елларда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә заманча шәһәр тирәлеген формалаштыру муниципаль программасын эшләү, «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә электрон рәвештә сайлау мөмкинлеген тәэмин итә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:// pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.И. Исламовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — С.Ю. Зайцев